

Язма героебыз инвалидлыкны нормаль тормыш юлында ахыргы хо-кем карары дип санамый. Әйе, ул, һичшиксез, кешене момкинчелекләрдә чикли. Әмма Ләмберә районы Кривозерье авылында яшәvче Рафик Альшин очен vзенә һәм башкаларга анын нәрсәгә сәләтле булуын, анын холкы һәм рух коче ни дәрәҗәдә нык булуын раслау моһимрәк.
«Халыкны социаль яклау» оешмасы директоры Галия Харис кызы Батршина хәбәр иткәнчә, vткән елда Ләмберә районында кешеләргә авыр тормыш шартларында яшәргә момкинлек бирә торган 211 социаль контракт то-зелгән. Быел да социаль контракт тозv мәсьәләсе буенча кешеләр мо-рәҗәгать итә. Программа 2021 елда да гамәлдә булачак. Социаль контракт дvрт юнәлеш буенча пособиеләр бvлеп бирvне кvздә тота, шул исәптән хәтта кешене башка белгечлек буенча янадан укытуга да.      Аз керемле авыл гаиләләре бюджеттан бvлеп бирелгән акчага, кагыйдә буларак, мал-туар сатып ала. Һәм шунын аркасында vзләрен азык-толек белән тәэмин итеп кенә калмыйча, vз йорт фермаларыннан артык продукция не сатып, бераз акча да эшли алалар. Шулай, Кривозерье авылында гомер итvче Рафик Альшиннын да ике танасы һәм алты vгезе социаль контракт ярдәме белән барлыкка килгән. Программа буенча ана 250 мен сум акча бvлеп бирелгән. Бу акчалар терлек сатып алу очен генә тvгел, терлекчелек биналары тозv, терлек азыгы сатып алу очен дә кирәк булган.
- Киләсе язда ук таналарыбыз сыерлар булыр дип ометләнәбез, - дип сойли Рафик Альшин. - Ул вакытта безнен vз сотебез булачак. Ә аннан, эремчек, каймак, май ясарга була... гаиләбезгә, бигрәк тә балаларга, бу барысы да файдага гына булачак.
Альшиннарнын әлегә ике кызы бар. Әмма тиздән гаилә артачак. Республика балалар хастаханәсендә эшләvче Рафикнын хатыны Ольга оченче балага йокле. Табиблар кыз булачак, дигәннәр. Гаилә башлыгы мондый вакыйгага соенә, чонки кызлар белән жинелрәк, ди. Үсеп житкән кызлар инде әтиләренә хужалык эшләрендә актив булышалар.
Яшерен-батырын тvгел, кvпчелек аз керемле гаиләләрдә социаль тvләvләр һәм пособиеләр бердәнбер керем чыганагы булып тора. Альшиннар гаиләсендә дә шулай. Рафик vзе икенче группа инвалиды (гаилә башлыгынын бер кулы һәм бер аягы зәгыйфьләнгән…), пенсиясе кечкенә. Хатыны Ольганын да хезмәт хакы - минималь.
Ой хужалыгыгызны ничек башкарып чыгасыз, сез бит физик хезмәтегездә чикләнгән, дигән сорауга Рафик Альшин:
- Мин бит ир-ат, - дип жавап бирә ул. - Инвалид дип гомер буе мендәргә еларгамы? Кыен! Әйе, кыен була, ә авылда кемгә жинел? Жайлашам, барлык катлаулы эшләрне дә мостәкыйль башкарырга тырышам. Абыема рәхмәт, ул мина терлек азыгы белән булыша…

Якын киләчәктә Рафик Альшиннын vз ой фермасында могезле эре терлек санын арттыру планда тора. Анын тагын бер кызыклы хыялы бар - хужалык очен тәгәрмәчле трактор сатып алырга һәм анда эшләргә ойрәнергә. Анын сvзләренә караганда, техника белән булачак мини-фермасын vстерv жинелрәк булачак. Әйтик, Кривозерье авылы зур, анда менгә якын кеше яши. Ә мал vстерvче аз. Мәсәлән, ул яши торган зур урамда барлыгы биш баш сыер асрыйлар. Шуна анын сотен авыл халкы бик теләп сатып алачаклар, чонки ана ихтыяж бар. Артык сыер ите сату белән дә кыенлыклар булмаячак, дип уйлый фермер. Теләсән, бар нәрсәне булдырып була.

**Наилә Насырова**